СОВЕТ ВАХИТОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.28, д. им. М. Вахитова,
422575

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ВАХИТОВ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Үзәк ур., 28 нче йорт, М. Вахитов исем авылы,
422575

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.


РЕШЕНИЕ　　　　　　　　　　КАРАР

26-129　　　　Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379　　　　24.10.2022

д. им. М. Вахитова

Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре, даими нигездә үз вәкаләтләрен башкаручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затлары, депутатларның хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасында даими нигездә үз вәкаләтләрен башкаручы муниципаль берәмлекләр башлыкларын, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларын, депутатларны, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларын, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләрен һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфа окладларын айлык акчалата бүләкләү күләмнәрен арттыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 22 августындагы 881 номерлы карары нигезендә, Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге Уставы белән

Югары Ослан муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Вахитов авыл Советының 2018 елның 24 апрелендәге 42-188 номерлы карары белән расланган Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт хакына җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәт хакына чыгымнар формалаштыру нормативларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарга 1нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Югары Ослан муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге Советының
2022нче елның 24 октябреннән
26-129 номерлы карарына
1 кушымта

Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләме

| Вазифа атамасы | Вазыйфаи оклад күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Башкарма комитет секретаре | 15904,00 |

1.2. Карарга 12нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Советының 2022нче елның 24 октябреннән 26-129 номерлы карарына
12 нче кушымта

Вахитов авыл җирлеге башлыгының акчалата түләү күләме

| Вазифа атамасы | Акчалата бүләкләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Җирлек башлыгы | 16389,00 |

2. Әлеге карар 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге Советының закон һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе
Югары Ослан муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге башлыгы Ф.Р. Каримов